# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Татарстан Республикасы Президентының үз вазыйфаларына керешүе турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

<u>1 статья.</u> 1991 елның 4 июлендәге "Татарстан Республикасы Президентының үз вазыйфаларына керешүе турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советының жыелма басмасы, 1992, N 2) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 2 статьяны түбәндәгечә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Президенты үз вазыйфаларына ке-керешкәндә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының пленар сессиясендә түбәндәгечә ант итә:

"Татарстан Республикасы халкына турылыклы хезмәт итәргә, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, Татарстан Республикасының суверенитетын тәэмин итәргә, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә, Татарстан Республикасы Президентының үземә йөкләнгән югары вазыйфаларын намус белән үтәргә тантаналы төстә ант итәм".

2. 5 статьяны түбәндәгечә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Президенты, Президент советы һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы башка консультатив органнар, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты Аппараты эшчәнлеген финанслау Татарстан Республикасының республика бюджеты средстволары исәбенә гамәлгә ашырыла. Татарстан Рес-

публикасы Президентының эшчәнлеген тәэмин итү мәсьәләләре Татарстан Республикасы законнары тарафыннан җайга салына".

3. 7 статьяда "сурәтләнгән" сүзе алдыннан "Дәүләт гербы" дигән сүзләр өстәргә.

4. 8 статьяда "Татарстан Республикасы Вице-президенты" дигән сүзләрне төшереп калдырырга, "аларның гаиләләре" сүзләрен "аның гаиләсе" сүзләренә алмаштырырга.

2 статья. Әлеге Закон басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 6 марты
№ 462